КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2019 ел, 25 декабрь | г.Казань | № 1204

«Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче; 2015 ел, 29 сентябрь, 725 нче; 2015 ел, 13 октябрь, 763 нче; 2016 ел, 26 август, 595 нче; 2018 ел, 22 август, 684 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1280 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлар буенча 471,81 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 27 берәмлек итеп;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең агентлык җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган өч урынбасары (шул исәптән бер беренче урынбасары) була дип.»;

әлеге карар белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы структурасын яңа редакциядә (кararга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 24 октябрь, 902 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 25 декабрь, 1204 нче
карары редакциясендә)

## Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы структурасы

